РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 7 нче октябре** **Чистай шәһәре** **№39/2**

Чистай шәһәр Советының 2013 елның 12 ноябрендәге
26/4 номерлы “Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Чмстиай шәһәре”муниципаль берәмлегендә
бюджет процессы хакындагы нигезләмәне раслау
турындагы карар”га үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәләрне гамәлдәге законнар белән тәңгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Советының “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакындагы 2013 елның 12 ноябрендәге 26/4 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (Чистай шәһәр Советының 2014 елның 26 августындагы 33/2 номерлы, 2015 елның 7 августындагы 42/2 номерлы, 2016 елның 12 апрелендәге 5/2 номерлы карарлары, 2017 елның 7 августындагы 16\2 номерлы карарлары редакциясендә) әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (әлеге карар редакциясендә) үзгәрешләр Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чоры бюджетыннан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Чистай муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга (www.chistopol.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Советының Бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә Н.В.Миңнегалиевны йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И.Ксенофонтов

Чистай шәһәр Советының
2019 елның 7 октябрендәге
39/2 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә
Үзгәреш кертү

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяда:

5 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең Баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары тарафыннан эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;»;

6.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:
«3) муниципаль берәмлеккә карата, алар буенча Федераль закон нигезендә тиешле гавами-хокукый берәмлек мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын баш бүлүченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган тәкъдим итә.»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 7.1-7.4 статьяларын өстәргә:

7.1 нче статья. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бюджетына бирелә торган бюджетара трансферт формалары

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бюджетара трансфертлар формада бирелә:

муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән очракларда, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү;

муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;

башка бюджетара трансфертлар;

7.2 нче статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр

1. Чистай шәһәр Советы карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә кабул ителә торган карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатлары һәм шартлары Чистай шәһәр Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә төзелә торган җирле администрацияләр арасында килешүләр белән билгеләнә.

7.3 нче статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр.

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетында карала.

7.4. нче статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасының тиешле законнары нигезендә кабул ителә торган Чистай шәһәр Советы карарларында каралган очракта һәм тәртиптә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирелергә мөмкин»;

1.3.түбәндәге эчтәлекле 12.1 статьяны өстәргә:

«12.1. нче статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмәләр

1. Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмәләр буенча акча суммасы бурыч булып тора, аны бурычлы кеше Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмә нигезендә билгеләнгән датага түләргә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең финанс активларын формалаштыралар.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, районның финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

4. Акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләп хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән тиешле орган, яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Әгәр килешүдә башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге каршындагы акчалата йөкләмәләр, тиешле сумманы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетының бердәм счетына күчергәннән соң, үтәлгән булып санала.;

1.4. 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 нче статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары составына кертелә:

номиналь бәясе Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан килгән акчалар һәм аларны түләүгә юнәлдерелгән акчалар арасындагы аерма;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җәлеп ителгән һәм түләнгән Россия Федерациясе валютасындагы кредитлары арасындагы аерма;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җәлеп ителгән һәм түләнгән акчалары арасындагы аерма;

тиешле финанс елы дәвамында җирле бюджет акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү;

җирле бюджет кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын эчке финанслауның башка чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның башка формаларын сатудан кергән керемнәр;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары буенча курс аермасы;

Россия Федерациясе валютасында шәһәр гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме, гарант тарафыннан муниципаль гарантияләрне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, яки бенефициарның принципалга карата таләп хокукы гарантка юл кую белән бәйле булса;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең башка бурыч йөкләмәләрен түләүгә Россия Федерациясе валютасында җибәрелә торган акчалар күләме;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең юридик затларга бюджет Россия Федерациясе валютасындагы кредитлары бирү акчалар арасындагы аерма;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән, бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Россия Федерациясе валютасындагы бюджет кредитларының башка бюджетларына бирелгән суммасы арасындагы аерма;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм счеттан күчерелгән акчалар һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм счетка күчерелгән акчалар арасындагы аерма.

Агымдагы финанс елы башына шәһәр бюджеты акчаларының калдыклары, шәһәр Советының хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә, агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре”муниципаль берәмлеге исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә тотылырга мөмкин. Финанс хисап елында әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә, түләнергә тиешле муниципаль контрактлар күләмендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге исеменнән төзелгән, шәһәр бюджеты турында шәһәр Советы карары белән каралган очракларда, күрсәтелгән максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган очракта.

Калган акчалар белән идарә итү операцияләре составына Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм счетта гамәлгә куючысы булып торган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре”

муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасында шәхси счетлары ачылган оешмаларның акчаларын җәлеп итү һәм кире кайтару кертелә.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын тышкы финанслау чыганаклары составына кертелә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән һәм Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге тарафыннан түләнгән чит ил максатчан кредитларын куллану кысаларында бирелгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китерсә, максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында, Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән чит ил валютасында шәһәрнең муниципаль гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме.»;

1.5. 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең муниципаль бурычы

14.1. Муниципаль бурыч – муниципаль бурыч алулардан, өченче зат йөкләмәләре буенча гарантияләрдән барлыкка килә торган йөкләмәләр, шәһәр тарафыннан кабул ителгән Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән бурыч йөкләмәләре төрләре нигезендә башка йөкләмәләр.

14.2 Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләре түбәндәге төрдәге йөкләмәләр рәвешендә булырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең кыйммәтле кәгазьләренә (муниципаль кыйммәтле кәгазьләргә);

2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

3) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында чит ил валютасында Россия Федерациясеннән җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

4) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге тарафыннан кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән кредитлар;

5) Россия Федерациясе валютасындагы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге гарантияләренә (муниципаль гарантияләргә);

6) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында, чит ил валютасында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән муниципаль гарантияләргә;

7) Россия Федерациясе Бюджет кодексын гамәлгә керткәнче барлыкка килгән һәм муниципаль бурыч дип исәпләнгән башка бурыч йөкләмәләренә туры килә торган

бурыч йөкләмәләре.

Муниципаль бурыч күләменә кертелә:

1) муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка кертелгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) шәһәр тарафыннан җәлеп ителгән кредит оешмаларыннан кредитлар буенча төп бурыч күләме;

4) муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең түләнмәгән башкак бурыч йөкләмәләре күләме.

Муниципаль эчке бурыч күләменә түбәндәгеләр кертелә:

1) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән, кредит оешмаларыннан Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;

4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясе валютасында түләнмәгән башка бурыч йөкләмәләре күләме.

Муниципаль тышкы бурыч күләменә кертелә:

1) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында, Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге тарафыннан чит ил валютасында бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында, Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенә бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләре кыска вакытлы (бер елдан кимрәк), уртача вакытлы (бер елдан биш елга кадәр) һәм озак вакытлы (биш елдан алып 10 елга кадәр) булырга мөмкин.»;

14.3. Әгәр Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәсе түләү шартлары белән каралган, түләү датасыннан соң өч ел эчендә түләүгә тапшырылмаса (йөкләмә шартлары һәм шәһәрнең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән гамәлләр кредитор тарафыннан үтәлмәсә), күрсәтелгән йөкләмә тулысынча туктатылган дип санала һәм, әгәр дә Чистай шәһәр Советының муниципаль хокукый актларында башкасы каралмаган булса, муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең муниципаль гарантияләр буенча Россия Федерациясе валютасындагы бурыч йөкләмәләре муниципаль гарантияләрне туктатуга нигез булып торган вакыйгалар (хәлләр) килеп туганда, тулысынча туктатылган дип санала һәм күрсәтелгән вакыйгалар (әлеге вакыйгалар килеп чыгу турында белешмәләр тәкъдим итү) килеп туган очракта, муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.

2. Чистай шәһәр башкарма комитеты, әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән сроклардан соң, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен муниципаль бурычтан төшереп калдыру турында муниципаль хокукый акт кабул итә.

3. Муниципаль бурычтан төшереп калдыру, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән исәпкә алына торган муниципаль бурыч йөкләмәләре төрләре буенча җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәптән төшерү суммаларын чагылдырмыйча аларны исәптән төшерү суммасына муниципаль бурыч күләмен киметү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацының, 2 һәм 3 пунктларының гамәлдә булуы кредит килешүләре буенча Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм башка муниципаль берәмлекләр алдында муниципаль бурыч йөкләмәләренә кагылмый.

5. Муниципаль бурыч йөкләмәләренең реструктуризацияләнгән, шулай ук түләнгән (сатып алынган) муниципаль бурыч йөкләмәләрен төшереп калдыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 һәм 113 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең эмиссия шартлары нигезендә, аларны тулы күләмдә эмитлаштырган орган тарафыннан сатып алынган (Россия Федерациясе законнарында каралган операцияләрне алмаштыру нәтиҗәсендә, яисә башка операцияләр) муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең чыгарылышлары, түләү датасына кадәр, күрсәтелгән орган карары буенча вакытыннан алда түләнгән дип танылырга мөмкин.

Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты үзе чыгарган муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча йөкләмәләрне (Россия Федерациясе законнарында каралган операцияләрне алмашу, яисә бүтән операцияләр нәтиҗәсендә алынган) түләп бетерү датасына кадәр сатып алынган дип танырга хокуклы.»;

1.6. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 Статья. Муниципаль бурыч алу.

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә җирле бюджетка заем акчаларын җәлеп итүне күздә тота, алар буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең заемчы буларак, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең муниципаль тышкы бурыч алулары дигәндә, Россия Федерациясе максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында район исеменнән җирле бюджетка федераль бюджеттан кредитлар җәлеп итү күздә тотыла, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясе алдында чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре шулар буенча барлыкка килә.

3. Муниципаль тышкы бурыч алулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең Дәүләт тышкы бурыч алулары программасына кертелгән проектларны финанслау максатларында гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашыру хокукына Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты ия.

5. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге тарафыннан түбәндәге шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырыла:

1) районның бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлар булмау;

2) Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган юридик затларның бер, яисә берничә рейтинг гамәлләрен башкара торган дәрәҗәдән ким булмаган кредит рейтингы алуы.

6. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә бурыч тотрыклыгының уртача дәрәҗәсе булган заемчылар төркеменә кергән очракта, муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашырырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 5 пунктында каралган районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләрен арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел, аның аркасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеген бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кертергә мөмкинлек бирә.

7. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә бурыч тотрыклыгының уртача дәрәҗәсе булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашырырга, муниципаль гарантияләрне бары тик Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән очракта гына бирергә хокуклы, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль гарантияләрне, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр кертүне күз алдында тота.

8. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, аны, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә, бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашырырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 5 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль

берәмлегенең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләрен арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.

9. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә, бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә керткән очракта, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан бюджет кредитлары алу рәвешендә гамәлгә ашырырга хокуклы, ул Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең түләү сәләтен торгызу планы кысаларында бирелгән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 9 пунктында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясындагы 7 пунктында каралган.

10. Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә, бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кергән очракта, муниципаль тышкы бурыч алуларны гамәлгә ашырырга һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында бирергә хокукы юк.

11. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $31^1$ статьясы нигезендә, бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кергән очракта, бары тик Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының  рөхсәтен алып, муниципаль эчке бурыч алуларны гамәлгә ашырырга, муниципаль гарантияләрне чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр расланган очракта гына бирергә хокуклы.

12. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чстай шәһәре” муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 9 пунктында каралган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре”муниципаль берәмлегенең түләү сәләтен торгызу планы кысаларында бирелгән максатчан бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен реструктуризацияләүне уздыру рөхсәт ителми.»;

1.7. түбәндәге эчтәлекле 15.1-15.7 статьяларын өстәргә:

«15.1. Статья. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең чит ил валютасында бурыч алуларын гамәлгә ашыру һәм гарантияләрне бирү үзенчәлекләре.

1. Татарстан Республикасы  Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясеннән чит ил валютасында бурыч алырга, Россия Федерациясеннән җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитларын Россия Федерациясе тарафыннан куллану кысаларында гына, чит ил валютасында гарантияләр бирергә хокуклы».

15.2. Статья.  Муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме.

1. Тиешле финанс елына муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме дигәндә, тиешле финанс елына муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алу программалары буенча җирле бюджетка акча җәлеп итүнең җыелма күләме аңлашыла.

2. Җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары белән билгеләнә, һәм тиешле финанс елында акчаларны җәлеп итүнең гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга җибәрелә торган акчаларның гомуми суммасыннан һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирле бюджет турындагы карар белән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле финанс елына расланган бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артмаска тиеш.

3. Хисап финанс елында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып киткән очракта, агымдагы елның 1 гыйнварына җирле бюджет акчаларының күрсәтелгән арттыру суммасында барлыкка килгән калдыклары, агымдагы финанс елына бурыч алуларның иң чик күләмен киметеп, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында каралган максатларга юнәлдерелергә тиеш.

